ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясындагы 1 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 11 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 12 (II өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле $8^3$ – $8^5$ пунктларны өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«$8^3$) Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар – Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә мобилизация буенча хәрби хезмәт узу чорында;

$8^4$) ихтыярый формированиедә катнашу турында (Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ихтыярый ярдәм күрсәтү турында) контракт төзегән гражданнар, әгәр алар Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Херсон һәм Запорожье өлкәләре территорияләрендәге махсус хәрби операциядә катнашса, – ихтыярый формированиедә катнашу турында (Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ихтыярый ярдәм күрсәтү турында) контракт гамәлдә булу чорында;

$8^5$) әлеге өлешнең $8^3$ – $8^4$ пунктларында күрсәтелгән гражданнарның гаилә әгъзалары:

а) ата-аналар (уллыкка алучылар);

б) хатыны (ире);

в) балигъ булмаган балалар, шул исәптән уллыкка алынган, тәрбиягә алынган һәм опекада (попечительлектә) торучы балалар;

г) 18 яшенә җиткәнче инвалид булган 18 яшьтән өлкәнрәк балалар;

д) көндезге уку рәвешендә мәгариф оешмаларында белем алучы 23 яшькә кадәрге балалар;

е) аларның тәрбиясендә булган затлар;» .

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 26 декабрь
№ 102-ТРЗ